| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 г. Заинск №462

**«2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше, актуаль социаль, иҗтимагый әһәмияткә ия проблемаларын хәл итүдә иҗтимагый оешмалар мөмкинлекләрен нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыру максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 маендагы 281 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 458 номерлы, 2021 елның 13 апрелендәге 220 номерлы, 2021 елның 19 июлендәге 469 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаны финанслау чыганаклары һәм күләмнәре» 7 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 7.Программаны финанслау чыганаклары һәм күләмнәре | Программа кысаларында СО НКО һәм гражданнарга муниципаль бюджет акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү чаралары түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: |

| | |
|---|---|
| | 2019 ел – 1578250 сум,<br>2020 ел – 834100 сум,<br>2021 ел – 2300000 сум. |

1.2. «Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программаны финанслауның гомуми күләме муниципаль бюджеттан 4712350 сум тәшкил итә

| Финанслау чыганаклары | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | Барысы |
|---|---|---|---|---|
| Муниципаль бюджеттан | 1 578 250 | 834 100 | 2 300 000 | 4 712 350 |
| Программа буенча барысы | 1 578 250 | 834 100 | 2 300 000 | 4 712 350 |

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс чорына муниципаль бюджет формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

1.3. Раздел «Программа чаралары» VI бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Чараларның исеме | Программаны тормышка ашыру чыгымнары суммасы (сумн.) | | | Барысы (сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | |
| **Ветераннар советы** | | | | | |
| 1 | Ветераннарга фатирларын төзекләндерүдә матди ярдәм күрсәтү | 70 000 | - | 100 000 | 170 000 |
| 2 | Транспорт чыгымнары: чараларда катнашучыларны йөртү | 20 000 | - | - | 20 000 |
| 3 | Бөек Ватан сугышы ветераннарын юбилейлары белән котлау (90, 95, 100 яшь тулу уңаеннан) | 180 000 | 100 000 | 93 000 | 373 000 |
| 4 | Ветераннарга газета яздыруны оештыру | 70 000 | 37 500 | 80 000 | 187 500 |
| 5 | Эш йомгаклары буенча бүләкләү: рәисне 10 000 сум х 4 квартал = 40 000 сум секретарьны:<br>2019 ел: 2 000 сум х 4 квартал = 8 000 сум.<br>2020 ел: 2 500 сум х 4 квартал = 10 000 сум.<br>2021 ел: 2 000 сум х 4 квартал = 8 000 сум. | 48 000 | 50 000 | 48 000 | 146 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6 | «Җиңү» бәйрәмен үткәрү<br>Ветераннарны сыйлауны оештыру<br>2019 ел:160 кеше х 500 сум = 80 000 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел: - | 80 000 | - | - | 80 000 |
| 7 | Өлкәннәр көне уңаеннан үзәк район хастаханәсендә дәваланучы өлкән яшьтәге кешеләрнең хәлен белү.<br>Азык-төлек җыелмасы:<br>2019 ел: 80 кеше х 350 сум = 28 000 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел: - | 28 000 | - | - | 28 000 |
| 8 | Интернат-йортларда яшәүче өлкән яшьтәге кешеләрнең урынга барып хәлен белү<br>2019 ел: 2 х 400 = 800 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел: - | 800 | - | - | 800 |
| 9 | Бөек Ватан сугышында катнашучыларга азык-төлек җыелмалары:<br>2019 ел:22 кеше х 2900 сум = 63 800 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел: - | 63 800 | - | - | 63 800 |
| | **БАРЫСЫ:** | **560 600** | **187 500** | **321 000** | **1 069 100** |
| **Инвалидлар җәмгыяте** | | | | | |
| 1 | Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү<br>2019 ел:10 кеше х 2500 сум = 25 000 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел:14 кеше х 2500 сум = 35 000 сум. | 25 000 | - | 35 000 | 60 000 |
| 2 | Газеталарга яздыруны оештыру | 30 000 | 16 100 | 34 200 | 80 300 |
| 3 | Инвалидлар декадасын әзерләү һәм үткәрү: сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен бәйрәм, «Шатлык» халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең максатчан төркеменә, «Чукрак-телсезләр» клубына йөрүчеләр өчен<br>2019 ел:100 кеше х 200 сум = 20 000 сум.<br>2020 ел: 40 кеше х 250 сум = 10 000 сум.<br>2021 ел:100 кеше х 300 сум = 30 000 сум. | 20 000 | 10 000 | 30 000 | 60 000 |
| 4 | Кызыксынулар буенча клубларда бәйрәм очрашуы: «Танышу» клубы, «Колясочник» клубы<br>Ашату, чәй эчертүне оештыру<br>2019 ел: 40 кеше х 130 сум = 5 200 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел: 60 кеше х 150 сум = 9 000 сум. | 5 200 | - | 9 000 | 14 200 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Халыкара инвалидлар көнен бәйрәм итүгә багышланган чара.<br>Ашатуны оештыру. | 30 000 | - | 40 000 | 70 000 |
| 6 | Эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү<br>- җәмгыять рәисе: (10 000 сум) х 3 квартал = 30 000 сум.<br>- җәмгыятьнең секретаре: (8 000 сум) х 4 квартал = 32 000 сум. | 32 000<br>20 000 | 32 000<br>20 000 | 30 000<br>32 000 | 94 000<br>72 000 |
| 7 | Телефон элемтәсе өчен түләү | 6 000 | 7 000 | 7 000 | 20 000 |
| 8 | Канцелярия товарлары сатып алу | 4 000 | 4 000 | 4 000 | 12 000 |
| 9 | Түләүсез чәч кистерү:<br>2019: 40 кеше х 200 сум = 8 000 сум.<br>2020: 20 кеше х 200 сум = 4 000 сум.<br>2021: 40 кеше х 200 сум = 8 000 сум. | 8 000 | 4 000 | 8 000 | 20 000 |
| 10 | Эш сәфәре чыгымнары | 5 000 | - | - | 5 000 |
| 11 | Инвалидлар өчен пандуслар, тоткалар һәм култыксалар урнаштыру | - | - | 177 700 | 177 700 |
| | **БАРЫСЫ:** | **185 200** | **93 100** | **406 900** | **685 200** |
| **Сукырлар җәмгыяте** | | | | | |
| 1 | Республика слетында катнашу<br>Эш сәфәре чыгымнары (юл билетлары) | 1 000 | 1 000 | 3 000 | 5 000 |
| 2 | Инвалидлар өчен спорт ярышларында һәм фестивальләрдә катнашу<br>Эш сәфәре чыгымнары | 3 000 | - | 6 000 | 9 000 |
| 3 | Авыр тормыш хәлендә калган җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү:<br>2019 ел:10 кеше х 2000 сум = 20 000 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел:10 кеше х 2000 сум = 20 000 сум. | 20 000 | - | 20 000 | 40 000 |
| 4 | Җәмгыять әгъзаларын газетага яздыруны оештыру | 10 000 | 5 500 | 12 100 | 27 600 |
| 5 | Кар сәләте буенча инвалидларга күзлек алуга матди ярдәм күрсәтү | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 30 000 |
| 6 | «Ак таяклылар көне»нә әзерлек һәм аны уздыру. 20 кешегә чәй өстәле көйләү | 6 000 | 6 000 | 6 000 | 18 000 |
| 7 | Күрү сәләте чикләнгән балалар өчен инвалидлар декадасы һәм Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан чаралар әзерләү һәм уздыру<br>Ашатуны оештыру:<br>2019 ел: 25 кеше х 250 сум = 6 250 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел: 25 кеше х 250 сум = 6 250 сум. | 6 250 | - | 6 250 | 12 500 |
| 8 | Хуҗалык чыгымнары<br>Канцелярия товарлары сатып алу | 5 000 | 5 000 | 5 000 | 15 000 |
| 9 | Җәмгыять рәисен эш йомгаклары буенча бүләкләү<br>4 квартал х 10 000 сум = 40 000 сум. | 32 000 | 32 000 | 40 000 | 104 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Юл йөрү билетын түләү | 5 832 | - | - | 5 832 |
| 11 | Интернет өчен түләү | 12 240 | 12 240 | 12 240 | 36 720 |
| | **БАРЫСЫ:** | **111 322** | **71 740** | **120 590** | **303 652** |
| **«Чернобыль берлеге» иҗтимагый оешмасы** | | | | | |
| 1 | Ветераннарны газетага яздыруны оештыру | 5 000 | 2 760 | 6050 | 13 810 |
| 2 | ЧАЭСта һәлакәт уңаеннан Хәтер көнен оештыру һәм үткәрү (26 апрель)<br>Иҗтимагый оешма ветераннарына матди ярдәм күрсәтү<br>2019 ел:100 кеше х 500 сум = 50 000 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел:93 кеше х 500 сум = 46 500 сум.<br>Һәйкәлгә кую өчен чәчәкләр сатып алу<br>Район газеталарында белдерүләр бастырып чыгару | 50 000<br><br><br><br><br><br>4 000<br>- | -<br><br><br><br><br><br>-<br>- | 46 500<br><br><br><br><br><br>10 400<br>1 500 | 96 500<br><br><br><br><br><br>14 400<br>1 500 |
| 3 | Авыр тормыш хәленә юлыккан җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү<br>2019 ел:5 кеше х 2000 сум = 10 000 сум.<br>2020 ел: -<br>2021 ел:12 кеше х 2000 сум = 24 000 сум. | 10 000 | - | 24 000 | 34 000 |
| 4 | Эш йомгаклары буенча җәмгыять рәисен бүләкләү<br>2 квартал х 6 000 сум = 12 000 сум. | 24 000 | 24 000 | 12 000 | 60 000 |
| | **БАРЫСЫ:** | **93 000** | **26 760** | **100 450** | **220 210** |
| **Гражданнарга социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар** | | | | | |
| 1 | Мохтаҗ гражданнарга матди ярдәм күрсәтү | 613 128 | 440 000 | 729 060 | 1 782 188 |
| 2 | Сәяси золым корбаннарын искә алу көне (30 октябрь)<br>Матди ярдәм:<br>2019 ел: 30 кеше х 500 сум = 15 000 сум.<br>2020 ел: 30 кеше х 500 сум = 15 000 сум.<br>2021 ел: 16 кеше х 500 сум = 8 000 сум. | 15 000 | 15 000 | 8 000 | 38 000 |
| 3 | Аерым категория гражданнарның иминлеген тәэмин итү (автоном янгын турында хәбәр итү приборы (АПИ) урнаштыру)<br>АПИ - 330 данә х 260 сум = 85 800 сум.<br>АПИ - 1900 данә х 278 сум = 528 200 сум. | - | - | 85 800<br>528 200 | 85 800<br>528 200 |
| | **БАРЫСЫ** | **628 128** | **455 000** | **1 351 060** | **2 434 188** |
| | **ПРОГРАММА буенча БАРЛЫГЫ** | **1 578 250** | **834 100** | **2 300 000** | **4 712 350** |

1.4. «Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» VII бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Ярдәмче программаларның исемнәре | Төп чараларның исемнәре | Башкару чылар | Төп чараларны башкару сроклары | Индикаторларның күрсәткечләре | | | Чыганакларны күрсәтеп, финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| Ветераннарга матди ярдәм күрсәтү буенча чаралар | - Ветераннарга фатирларын төзекләндерүгә матди ярдәм күрсәтү;<br>- Транспорт чыгымнары: чараларда катнашучыларны йөртү;<br>- БВС ветераннарын юбилейлары белән котлау (90, 95, 100 яшь);<br>- Ветераннарга газета яздыруны оештыру;<br>- Җәмгыять рәисен, җәмгыять секретарен эш йомгаклары буенча бүләкләү;<br>- «Җиңү» бәйрәмен үткәрү. Ветераннарны хөрмәтләүне оештыру;<br>- Өлкәннәр көне уңаеннан Зәй үзәк район хастаханәсендә ятучы өлкәннәр янында булу. Азык-төлек җыелмасы;<br>- Интернат-йортларда яшәүче өлкән яшьтәге | ЗМР Башкарма комитеты, подрядчы оешма, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | 2019-2021 еллар | 9 | 3 | 4 | 560 600 | 187 500 | 321 000 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кешеләр янына бару;<br>- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга азык-төлек җыелмалары әзерләү. | | | | | | | | |
| Инвалидларга матди ярдәм күрсәтү чаралары | - Мөмкинлекләре чикләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү;<br>- Газеталарга язылуны оештыру;<br>- Инвалидлар декадасын оештыру һәм үткәрү: сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен бәйрәм, «Шатлык» халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең максатчан төркеменә, «Чукрак-телсезләр» клубына йөрүчеләр өчен;<br>- Кызыксынулар буенча клубларда бәйрәм очрашуы: «Танышу» клубы, «Коляскалы» клубы<br>Ашату, чәй эчертүне оештыру;<br>- Халыкара инвалидлар көнен бәйрәм итүгә багышланган чара.<br>Ашатуны оештыру; | ЗМР Башкарма комитеты, инвалидлар җәмгыяте, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | 2019-2021 еллар | 10 | 6 | 10 | 185 200 | 93 100 | 406 900 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | -Җәмгыять рәисен, җәмгыять сәркатибен эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү;<br>- Телефон элемтәсе өчен түләү;<br>- Канцелярия товарлары сатып алу;<br>- Бушлай чәч кистерү;<br>- Эш сәфәре чыгымнары;<br>-Инвалидлар өчен пандуслар, тоткалар, култыксалар урнаштыру. | | | | | | | | |
| Күрү сәләте буенча инвалидларга матди ярдәм чаралары | - Республика слетында катнашу<br>Эш сәфәре чыгымнары (юл билетлары);<br>- Инвалидлар өчен спорт ярышларында һәм фестивальләрдә катнашу<br>Эш сәфәре чыгымнары;<br>- Авыр тормыш хәленә юлыккан җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү;<br>- Җәмгыять әгъзаларына газеталарга язылуны оештыру;<br>- Күрү сәләте буенча инвалидларга күзлек сатып алу өчен матди ярдәм күрсәтү;<br>- «Ак таяклылар көне»н оештыру һәм уздыру. 20 | ЗМР Башкарма комитеты, күрү сәләте буенча инвалидлар җәмгыяте, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | 2019-2021 еллар | 11 | 7 | 10 | 111 322 | 71 740 | 120 590 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кешегә чәй өстәле көйләү;<br>- Күрү сәләте чикләнгән балалар өчен инвалидлар декадасы һәм Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан чаралар оештыру һәм уздыру.<br>Ашатуны оештыру;<br>- Хуҗалык чыгымнары Канцелярия товарлары сатып алу;<br>- Җәмгыять рәисен эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү;<br>- Юл йөрү билетын түләү;<br>- Интернет өчен түләү. | | | | | | | | |
| ЧАЭСта һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга матди ярдәм чаралары | - Ветераннарга газетага язылуны оештыру;<br>- ЧАЭСта һәлакәт уңаеннан Хәтер көнен оештыру һәм үткәрү (26 апрель)<br>Иҗтимагый оешма ветераннарына матди ярдәм күрсәтү<br>Һәйкәлгә кую өчен чәчәкләр сатып алу<br>Район газеталарында игълан урнаштыру;<br>- Авыр тормыш хәленә юлыккан җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм | ЗМР Башкарма комитеты, «Чернобыль берлеге” иҗтимагый оешмасы,<br>ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | 2019-2021 еллар | 4 | 2 | 4 | 93 000 | 26 760 | 100 450 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтү;<br>- Җәмгыять рәисен эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү. | | | | | | | | |
| Матди ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның ярдәм күрсәтелмәгән категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары | - Мохтаҗ гражданнарга матди ярдәм күрсәтү;<br>- Сәяси репрессия корбаннарын искә алу көненә матди ярдәм (30 октябрь).<br>- Аерым категория гражданнарның иминлеген тәэмин итү (автоном янгын турында хәбәр итү приборы (АПИ) урнаштыру) | ЗМР Башкарма комитеты, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ның социаль яклау бүлеге | 2019-2021 еллар | 2 | 2 | 3 | 628 128 | 455 000 | 1 351 060 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

А.В. Чапков
(85558)3-41-22